| Республика Татарстан<br>Глава Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Иске Минзәләбаш авыл җирлеге<br>башлыгы |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел 8 ноябрь № 4

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлегенең Кужак авылында
2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.Кужак авылы гражданнарның 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне 2021 елның 19 ноябренә 14 сәгатькә Кужак мәдәният йортында билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Кужак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) Кужак торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Кужак торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү ( лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Кужак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

4) Җәйге чорда Кужак торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү )

5) Кужак торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

6) "Сарман" район гәҗитенә некрологлар бирү

7) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (биек үскән агачларны кисү);

ӘЙЕ ЮК?»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов